*Роберт Миңнуллин тәрҗемәләренең шигъри табигате*

*Минһаҗева Ләйлә Ихсановна,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы доценты*
*Казан Федераль университеты, Әдәбият һәм сәнгать институты, Казан*
*Leila69@inbox.ru*

Мәгълүм ки, тел, әдәбият тарихы, аның бүгенге торышы белән бәйле актуаль мәсьәләләр соңгы дистә еллар тарих, лингвистика, психология белән бәйле тикшеренүләрнең үзәгендә тора. Һәм ул, турыдан-туры бүгенге җәмгыятьтәге үзгәрешләр, экономик-политик шартлар белән бәйләнә: чор таләп иткәнчә, татар җәмәгатьчелегенә дә бүген әдәбиятара, мәдәниятара бәйләнешләрне киңәйтүләзем.

Шуңа бәйле рәвештә, татар балалар әдәбиятында да бүген тәрҗемә эшчәнлеге турында сөйләшү – көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

Тарихка мөрәҗәгать итсәк, XX гасырда бу юнәлештә әйдәп баручы талантларның берсе, әлбәттә, Г.Тукай. Аның тәрҗемә юнәлешендәге тәҗрибәсе үз вакытында һәм хәзер дә югары бәяләнә. Чөнки ул төрле халыклардан иң уңышлы әсәрләрне татар рухына, татар мөхитенә якын рәвештә тәрҗемә итә алды. Шагыйрьнең «Бала белән Күбәләк» (Л.Н.Модзалевский, «Мотылек»), «Таян Аллага» (И.С.Никитин, «Молитва дитя»), «Баскыч» (А.Е.Измайлов, «Лестница»), «Яхшы хәбәрләр» (А.Н.Плещеев, «Капля дождевая»), «Яңгыр» (А.Н.Майков, «Летний дождь»), «Карлыгач» (И.С.Никитин, «Гнездо ласточки») һ.б. шигырьләре, күп сандагы мәсәлләре ирекле тәрҗемә ителгән. Биредә Г.Тукайның шагыйрьлеге дә, оста тәрҗемәче булуы да ачыла. Чөнки шигырьләр татар дөньясына, татар әдәбиятына хас детальләр белән, милли аһәң белән сугарылган һәм иң мөһиме – югары сәнгать дәрәҗәсендә. Шушы ук фикерне Р.Миңнуллинның балалар өчен тәрҗемәләренә карата да әйтергә мөмкин. Аның тәрҗемәсендә рус, каракалпак, төрекмән, мари, чуаш, грузин, әрмән, казакъ, удмурт, литва шагыйрьләренең әсәрләре татар укучысына да якын:

Алып кайттым мин «икеле» –

Андый хәл сезгә таныш.

Әтинең чыкты ачуы,

Тик чыгармады тавыш.

... Бик борчый бу сөйләшмәү,

Юкка түгел бу дәшмәү! [2, б. 301].

Мәгълүм ки, чит телләрдән туган телгә тәрҗемә шактый авыр хезмәт. Чөнки этик һәм эстетик таләпкә тел чаралары ярдәмендә ирешелә, әмма эчтәлек, мәгънә шул ук калырга тиеш. Нәтиҗәдә, тәрҗемәченең туган телнең бөтен нечкәлекләрен белүе белән бергә, сүз остасы, чит милләтләр яшәешеннән дә шактый хәбәрдәр булуы мәҗбүри. Моңа өстәп, инде расланган, тел – аралашу коралы гына түгел, бәлки, һәр милләтнең үзенә генә мәгьлүм мирасы да. Чөнки тел – миллилек, мәдәният чагылышы, аның төп өлеше, яшь буынның формалашу шарты, милләтнең гасырларга сузылган яшәү коды да. Мондый шартларда бер генә халыкның да ни гади тормышы, ни рухи яшәеш үзенчәлекләре бөтенләе белән башка милләт вәкилләре тарафыннан кабул ителә алмый, әлбәттә. Әлеге хакыйкатьне аңлаган Р.Миңнуллинның «Дустымны эзлим» (Агагельды Алланазаров, төрекмәнчәдән) дип исемләнгән шигырь тәрҗемәсендә эт исемен дә татарчалап куюы аклана:

Дустым югалды бит әле!

Шундый әйбәт дус иде.

... Ятканда телен чыгара,

Ялтырап тора күзе.

Койрыгы пумала кебек,

Акбай исемле үзе [2, б. 290].

Шигырьне тәрҗемә әсәре дип әйтү бәхәс тә тудырыр кебек. Чөнки балалар шигърияте өлкәсендә күпеллык тәҗрибәбез күрсәткәнчә, тел, образлылык, балалар өчен шигырьләрдәге ритм-рифма, шигырь төзелеше үзенчәлекләре һәр милли мирасның үзәк өлеше булып тора, һәм, нәтиҗәдә,

башкалардан аерылып торучы этник – милли фикерләү дәрәҗәсе үзгәрәк булган халыкны аерып карау мөмкинлеге туа. Ә бу очракта без татар балалар поэзиясенә һәм Р.Миңнуллин иҗатына гына хас сыйфатлар белән очрашабыз. Ягъни, тәрҗемә эшчәнлегендә дә шагыйрьнең үз стиле, миллилек, халыкчанлык өстенлек итә:

Берни дә аңлый алмыйм,
Әллә ни булды башка.
Шунсы хак – велосипед
Тәтемәс миңа башка [2, б. 357].

Татар балалары тарафыннан үзара кулланылышта булган сүзләр (тәтемәс, сугыш чукмары, сыздыр тиз генә!), татар халкының сөйләм теленә хас чагыштырулар (пумала кебек), образлар тудыруда гади, уңышлы файдаланылган сыйфатламалар, җырлап торган ритм-рифма һ.б. – тәрҗемә әсәрләрендә дә шагыйрь талантын билгеләүче төп шартлар булып калган:

У-у-у... узыша-узыша,
Әй тузыша тузыша,
И кызыша-кызыша
Ике әтәч сугыша.
... Сугышып алар туйган –
Ике як та кул куйган
Солыхка, тынычлыкка!
Сугышканнар ла юкка! [2, б. 346].

Литва шагыйре Юозас Некрошюсның «Сугыш чукмарлары» шигыре тәрҗемәсендә, күренә ки, иҗади фантазия әдәби бөтенлекне тәшкил итә. Биредә сөйләмнең әдәби стиле образлылык белән генә характерланмый, бәлки, текстның эчке мәгънә төсмерен җиткерү бурычын да үти.

Акрым тикшеренүләр күрсәткәнчә, Р.Миңнуллинның балалар өчен иҗатында уен функция зур урын алып тора [1, 310б.]. Әлбәттә, бу юкка гына түгел. Шагыйрь шигырьләрен махсус рәвештә уенга әйләндерергә омтыла. Кече һәм урта яшьтәге балалар өчен ул, мәсәлән, шигъри формада сүзләр

белән уенны тәшкил итә: кыска яки озын шигъри юллар, ритм, рифма, бер үк яки охшаш авазларны кабатлау, антоним, омоним, синоним сүзләрне кулланып язу һ.б. Шигъри уен – характер ачу чарасы, психологик халәтне бирү алымы, зурларның «гаделсез» карашларына каршы чыгу чарасы буларак та Р.Миңнуллин поэзиясендә урын алды. Мондый үрнәкләр балаларга яңа төшенчәләр бирү һәм фикерләү сәләтен үстерү ягыннан да әһәмиятле. Фольклордагыча шигырләрьдә бер үк сүзнең, яки, яңгырашы белән охшаш сүзләрнең берничә тапкыр янәшә кабатлануы да отышлы. Мондый алым, әлбәттә, нәниләргә әсәрләрнең эчтәлеген тизрәк аңлау, яңа сүзләрне җиңелрәк үзләштерү мөмкинлеген ача. Әлеге алымны автор тәрҗемә эшчәнлегендә дә уңышлы файдалана:

Кәбестә татлы-татлы,
Чөнки ул катла-катлы [2, 347].
Яки,
– Әйдәле ит турагычка!
Әйдәле ит турагычка!
Туп-туры кит турагычка!
Туп-туры җит турагычка!
Туп-туры... марш! [2, 376].

Балалар психологиясе белән бәйле аерым специфик үзенчәлекләрне Р.Миңнуллин тәрҗемә эшчәнлегендә дә онытмый: балалар язучысы үзенең укучысы белән уенга керешкән очракта куйган максатына тизрәк һәм нәтиҗәлерәк ирешә, уенчыл лирик әсәрләр тизрәк ятлана, ачышлар да кызыклырак, көтелмәгәнчәрәк ясала:

Әбинең күзе күрми,
Җеп, ахры, шуңа керми.
Әбием шуны белми.
Энәсен миңа бирми [2, 334].

Чуашның мәгълүм, танылган шагыйре Юрий Семендернең «Яңгыр явар алдыннан» исемле шигырь тәрҗемәсе дә шактый кызыклы. [д], [р], [т] авазларының еш кабатлануы үзенә бертөрле яңгыраш тудыра:

Дөбер-дөбер

Дөберди –

Бөтен дөня

Дерелди.

Түшәм ишелер кебек

Түшәм тишелер кебек [2, б. 369].

Мондый төр лирик әсәрләрне уку дәвамында бала телнең яңгырашына игътибар итә, сүз ритмын ишетергә омтыла, кызыксына. Шигырьдәге гадәти күренеш–тасвирның эстетик тәэсир итү көче дә зур. «Д» авазының күп тапкырлар кабатлануы күк күкрәү, яшен яшнәүгә иярүне күрсәтә. Нәтиҗәдә шагыйрь кыска гына вакыт аралыгында тулы бер манзара тудыруга ирешә. Бер үк авазларны кабатлау шигырьнең музыкаль яңгырашын, аһәңен дә тәэмин итә.

Балалар шигърияте ул – гадәти тормыш күренешләрен, гадәти әйберләрне, әйләнә-тирәлекне «поэзияләштерү» аңа аерым мәгънә һәм матурлык бирү, әкияти шартлылык, әкияти әверелүләр, әлбәттә. Татар халык авыз иҗатына битараф булмаган шагырь, мөмкинлек чыкканда, аз күләмдә булса да, тәрҗемәләрдә дә әкияти алымнарга да мөрәҗәгать итәргә тырыша:

Малайлар бер көн көтте...

Алар ике көн көтте...

Өченче көн дигәндә...

Бер җимеш борын төртте [2, б. 306].

Үсеш дәвәменда һәр этносның яшь вәкиле үзе яшәгән тирәлек – конкрет җәмыятнең тарихи хәтерен, традицияләрен, гореф-гадәтләр, рухи кыйммәтләрен, яшәү нормаларын үзләштерә. Әлеге процесста туган тел, аның таләпләре дә өйрәнелә. Нәкъ менә шуңа күрә һәр халык вәкиле балалар өчен иҗатында үз теленең матурлыгын, музыкальлеген җырлый. Молдаван

шагыйре Григоре Виеруның да туган теленә ярату һәм хөрмәт хисләрен татар шагыйре уңышлы бирә алган:

Әгәр дә бик кирәк булса
Иң моңлы сүз, матур сүз,
Безнең туган телебездән
Алсын ул кош, әйтерсез! [2, б. 329].

Кечкенә яшьтә укылган шигырьләрнең бала өчен тормыш моделен тудырудагы роле бәхәссез. Нәкъ шуңа күрә булса кирәк, шагыйрьнең тәрҗемәләрендә «өй», «гаилә», «әти-әни» кебек һәр милләт өчен кадерле үзәк төшенчәләр еш кабатлана. Р.Миңнуллинга хас булганча, мондый әсәрләр арасында юмористик рух белән сугарылган шигырьләр дә байтак:

Кочаклап алды ул мине
Бөтен кызлар каршында...
Кочаклашмыйлар бит инде,
Мин хисле дип, һәр төштә.
Хиссез имеш. Кирәк аңа
Малай түгел, фәрештә [2, б. 295].

Ана образы бала хисләре аша бәян ителә, нәтиҗәдә, мондый садәлек елмайта. Тәрҗемәнең уңышы – Әнкәйләр турында үзе дә берничә дистә шигырь, җыр текстлары авторы булуга карамастан, Р.Миңнуллин А.Барто иҗатының төп үзлеген саклый алган.

Димәк, әйтелгәннәрдән чыгып фикер йөртсәк, һәр милләтнең балалар өчен әдәбияты бала акылы, танып белүе формалашуының аерылгысыз бер өлеше генә булып калмый, бәлки, ул үзенчәлекле милли-мәдәни күренеш тә. Мәгълүм ки, гасырлар дәвамында милли идеаллар, әхлакь принцилары аша милли әдәбиятлар формалаша. Төрле тарихи этапларда, географик шартлар белән дә бәйле, миллилек, гореф-гадәтләр, традицияләр кебек төшенчәләр ярдәмендә балалар күңеленә тәэсир итәрдәй нигезле психологик алымнар, чаралар туа һәм алар яшь буында милли үзаң формалашуда нигез булып тора. Мондый шартларда, әлбәттә, бу билгеләр тәрҗемә әсәрләренең үзәгендә

булырга тиеш кебек. Әмма, Р.Миңнуллинның уңышлы тәрҗемәләре аша балачак иле, сабыйларның дөньяны танып белүе, төрле милләт балаларының уйлары һәм теләкләре бердәй дәрәҗәдә охшаш һәм тәңгәл икәнлеге отышлы ачыла. Ягъни, Р.Миңнуллин тәрҗемә эшчәнлегендә телнең бөтен эчке мөмкинлекләреннән дә файдаланып эш итәргә омтыла дип нәтиҗә ясарга тулы нигез бар.

Әдәбият:

1. Минһаҗева Л.И. XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре / Л.И.Минһаҗева. – Казан: Хэтер, 2011. – 310 б.

2. Миңнуллин Р. Әсәрләр. Җиде томда. Т 4. / Р.Миңнуллин. Балалар өчен шигырьләр, кечкенә әкиятләр, ирекле тәрҗемәләр, төрле язмалар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. – 528 б.